**10 нчы сыйныфның рус төркеме өчен**

**татар теленнән I яртыеллык ахырына контроль эшләр**

**I вариант**

**1. Тест биремнәрен үтәгез**

***1) Нишләргә? Нишләмәскә? Сорауларына җавап бирүче фигыльне табыгыз.***
А) исем фигыль
Ә) инфинитив
Б) Шарт фигыль

***2) Исем фигыльнең юклык формасын табарга***

А) кермәү
Ә) укымаска
Б) баруларымны

***3) Нинди җөмлә җыйнак була?***

А) Баш һәм иярчен кисәкләрдән торган җөмлә.
Ә) Иярчен кисәкләрдән торган җөмлә.
Б) Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә.

***4) Сыйфат фигыль булган җөмләне күрсәтегез.***

А) Бу - минем яраткан эшем.
Ә) Марат театрга киткән.
Б) Оля безгә кунакка килде.

**2. Тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Кайсы малай яхшырак соң дип сораганнар

2) Патшаның ярдәмчесе әйткән әй ата акыллы тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме
3) Биби Хәят апа Лиза килде дип кычкырды

**3. Җөмләләрне җәенкеләндереп языгыз.**

1) Халык килә.
2) Мин киттем.
3) Театр башлана.
4) Мин киям.
5) Театрга баралар

**4. Җөмлә кисәкләрен билгеләгез.**

1) Сәламәт булу – үзе зур бәхет.
2) Озак йоклау – зарарлы.
3) Йокы алдыннан телевизор карау зыянлы.
4) Күпмедер вакыт узгач, кызның моңлы җыры тагын ишетелде

**5. Саннарны сүзләр белән языгыз.**

5, 18, 24, 207, 1021, 1890.

## II вариант

1. **Тест биремнәрен үтәгез.**

***1)Нишләүче? Нишли торган? Нишләгән? Нишләр? Нишләячәк? сорауларына җавап бирүче фигыль.***

А) исем фигыль

Ә) сыйфат фигыль

Б) хәл фигыль

***2)Кушма җөмләне табыгыз***

А) Ул бик матур итеп киенде һәм театрга китте.

Ә) Апалар кунактан кайткач та, без клубка киттек.

Б) Вәли белән икәү генә барган идек.

***3)Исем фигыль булган җөмләне табыгыз.***

А) Сәламәт булу өчен, беренче чиратта спорт белән шөгыльләнергә кирәк.

Ә) Дустың янына керү, хәлен белү кирәк.

Б) Сөйкемле, ягымл, чиста, матур, зәвык белән киенгән кеше күңелдә яхшы хисләр уята.

***4) Сөйләмдә еш кына хәбәрлек сүзләр белән кулланылучы фигыль.***

1) инфинитив

2) хикәя фигыль

3) сыйфат фигыль

2. **Тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Моны күргән беркатлы Лиза ах Хәят нинди матур син диде

2) А.П.Чехов кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш дигән

3) Халык дөньяда иң зур байлык сәламәтлек ди

3. **Җөмләләрне җәенкеләндереп языгыз**

1)Театрга баралар

2) Мин киям.

3) Китаплар алам.

4) Укытучы сөйләде.

5) Оля әйтте.

4. **Җөмлә кисәкләрен билгеләгез.**

1) Китап уку – файдалы.

2) Ютәлләү –авыру билгесе.

3) Тәмәке тарту – сәламәтлек өчен куркыныч.

4) Егет күзләрен ача, ак халатлы шәфкать туташы аның янында басып тора.

5. **Саннарны сүзләр белән языгыз.**

9, 15, 36, 418, 2095, 1983.